ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АНТОНОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

№11 23.04. 2021 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Антоновка авыл җирлеге Башкарма комитетының «Капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзү тәртибен һәм шартларын раслау хакында»гы 01.02.2021 елның 2 карары белән расланган капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияләрне комплексы үстерүне тәэмин итү максатларында үзгәрешләр кертү турында" 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Антоновка Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Антоновка Башкарма комитетының «Капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзү тәртибен һәм шартларын раслау турында» гы 01.02.2021 елның 2 номерлы карары белән расланган капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү:

1.1. 6 пунктның 6.1.пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләре (комплекслар), шулай ук күпфатирлы йортлар, торак йортлар (территорияне комплексы үстерү турындагы шартнамә нигезендә мондый йортлар төзү очракларыннан тыш) төзү (модернизацияләү, реконструкцияләү).

2. Әлеге карарны Антоновка авыл җирлегенең мәгълүмати стендларда игълан итәргә һәм Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе
Антоновка авыл җирлеге
ТР Спас муниципаль районы Башлыгы В. С. Фролов